**Шәһәр күләмендә**
**география фэненнән үткәрелә торган**
**олимпиаданың мәктәп этабы сораулары**
**2017-18 уку елы**

**9 нчы сыйныф**

**Эш вакыты – 180 минут**
**Гомуми балл – 72**

1. Россия составындагы республикаларның башкалаларын табыгыз
а) Армавир
б) Абакан
в) Сыктывкар
г) Биробиджан

2.Россиянең иң кырый көньяк ноктасы кайсы ил чигендә урнашкан?
а) Кытай
б) Әзербайжан
в) Казахстан
г) Грузия

3.Безнең илдә, XX гасырның беренче яртысындагы демографик кризис периодларын аерып алыгыз.
а)1905-1907
б)1914-1922
в)1924-1926
г)1933-1934

4.Икътисади актив халыкка керүче вариантларны күрсәтегез

а) эшләмәүче укучылар
б) эшсезләр
в) өй һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкта эшләүчеләр
г) эшләүче кешеләр

5.Россиядә яшәүче фин-угор группасы халыкларының  күпчелеге кайсы религияне тота

а) православие
б) ислам
в) католицизм
г) буддизм

6.Бирелгән республикалар арасыннан мәйданнары зуррак булган 2 регионны сайлап алырга

а) Карелия
б) Алтай
в) Коми
г) Бурятия

7.Нефть эшкәртү предприятияләренең урнашуына иң зур тәэсир ясаучы факторны табыгыз

а) чимал
б) хезмәт ресурслары
в) транспорт
г) әзер продуктны куллану

8.Россиянең кайсы икътисади районнарында күмер ачык ысул белән чыгарыла

а) Төньяк
б) Төньяк Кавказ
в) Көнчыгыш Себер
г) Ерак Көнчыгыш

9. “Елга – электростанция” пары туры килгән җавапны табыгыз.

а) Ангара – Красноярская
б) Дон – Каховская
в) Лена – Братская
г) Волга – Иваньковская

10.Россиядә күкерт табучы регионнарны атагыз

а) Самара өлкәсе
б) Оренбург өлкәсе
в) Архангельск өлкәсе
г) Иркутск өлкәсе

11.Кайсы бөртекле культура Россиядә иң күп чәчүлек мәйданын били?

а) арыш
б) бодай
в) арпа
г) солы

12.Кайсы өлкә Россиянең Үзәк икътисади районына керми
а) Орлов өлкәсе
б) Кострома өлкәсе
в) Белгород өлкәсе
г) Брянск өлкәсе

13.Артиллерия коралы ясау буенча әһәмиятле үзәкләр (артык вариантны аерып алырга)

а) Түбән Новгород
б) Екатеринбург
в) Пермь
г) Ковров

14. “Дуслык” нефтьүткәргече кайсы пунктлар аркылы үтә (артык җавапны тап)

а) Әлмәт
б) Тверь
в) Мичуринск
г) Пенза

15.Автобомиль транспортында йөк ташу тимер юл транспортына караганда: (дөрес җавапны табыгыз)

а) очсызрак
б) 2 тапкыр кыйбатрак
в) 5 тапкыр кыйбатрак
г) 10 тапкыр кыйбатрак

16.Әлеге картада нинди субъект күрсәтелгән? Бу регион, илнен кайсы субъектлары белән чиктәш?



17. Әзер продуктны әзерләү максатыннан, предприятияләрнең бергәләп җитештерүе нәтиҗәсе буларак туган производства элемтәләре ___________________________ дип атала.

18. Илнең, геополитик яктан урнашуын бәяләр өчен нинди критерийлар кулланыла?

19. Россия нинди минераль ресурсларга ярлы һәм безнең ил аларны башка илләрдән сатып алырга мәҗбүр?( икътисади яктан әһәмияткә ия 4 минераль ресурс исемен атарга)

20.Бирелгән рәсемдә, Россиянең кайсы регионының флагы күрсәтелгән? Рәсемдә нинди хайваннар сүрәтләнгән ?

